**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ СРЕДНЕДЕВЯТОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

422614 с.Среднее Девятово
ул. Сергеева, д.9
тел: 8-(84378)-3-41-11
факс: 8-(84378)-3-41-11
Sdev.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**УРТА ДЕВЯТОВО АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422614 а.Урта Девятово
Сергеев урамы, 9 нчы йорт,
тел: 8-(84378)-3-41-11
факс: 8-(84378)-3-41-11
Sdev.La@tatar.ru

**2024 елның 5 сентябре** **44номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Урта Девятово авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмә хакында» Урта Девятово авыл җирлеге Советының 2023 елның 23 гыйнварындагы 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024елның 08 августындагы 289-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлеге советы, КАРАР ИТТЕ**:**

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Урта Девятово авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмә хакында» Урта Девятово авыл җирлеге Советының 2023 елның 23 гыйнварындагы 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә, түбәндәге редакциядә бәян итеп:

4.6.4. пункт Планнан тыш күчмә тикшерү бары тик прокуратура органнары белән килештереп кенә үткәрелергә мөмкин, моңа 57 статьяның 1 өлешендәге 3 - 5 пунктлары һәм 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә уздыру очраклары керми.

4.9.5. пункт Күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында каралган карар кабул ителә алмый.

4.7.10 Пункт. Рейд тикшерүе прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, моңа 248 - ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3-5 пунктлары һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12_1 өлешләре нигезендә үткәрелгән очраклар керми

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб– адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Урта Девятово**
**авыл җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы** **К.М.Ипатова**